КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 13 ноябрь г.Казань № б-2520

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәрге чорга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итү чаралары планын («юл картасын») раслау турында» 2023 ел, 11 март, 238 нче карары белән расланган 2022 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәрге чорга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасының финанс тотрыклылыгын тәэмин итү чаралары планы («юл картасы») чаралары планының 3.4 пунктын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерциягә карамаган оешма счетында булдырыла торган капиталь ремонт фондының вакытлыча тотылмый торган акчасын урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 23 маендагы 453 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерциягә карамаган оешма счетында булдырыла торган капиталь ремонт фондының вакытлыча тотылмый торган акчасын урнаштыру кагыйдәләренең 3, 4, 5 пунктлары нигезендә, «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасының гамәлгә куючысы һәм югары коллегиаль идарә органы вәкаләтләре кысаларында:

1. «Татарстан Республикасының Торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – төбәк операторы) счетында булдырыла торган капиталь ремонт фондының вакытлыча тотылмый торган акча күләмен 400 млн.сумга тигез итеп билгеләргә.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 185 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә билгеләнгән төбәк операторы эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә карата таләпләр нигезендә капиталь ремонт фондының узган елда файдаланылмаган, төбәк оператор счетында (счетларында) барлыкка килгән, күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләреннән алынган акчаның калган өлеше рәвешендә тупланып баручы вакытлыча тотылмый торган акчаның иң чик күләмен 2023 елга 400 млн.сумга тигез итеп билгеләргә.

3. Төбәк операторга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төбәк операторы счетларын ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 23 маендагы 454 номерлы карары белән расланган Төбәк операторы счетларын ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә таянып кредит оешмасын сайлап алырга, шулай ук капиталь ремонт фондының төбәк операторы счетында тупланып баручы вакытлыча тотылмый торган акчасын бу боерыкның 1 пунктында билгеләнгән күләмдә Россия кредит оешмасында Россия Федерациясе валютасында банк кертеме (депозиты) шартнамәсе шарты буенча урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин